**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы карары**

**2016 елның 03 октябре** **№ 35**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Советы Су объектларының су саклау зонасын кулланганда, кешеләрнең ял итү урыннарында, күпләп торуларында булган хокук бозуларны кисәтү максатыннан карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Советының 30.09.2011 ел, № 31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә (алга таба-Кагыйдәләргә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. кагыйдәләрнең 7.9 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«7.9. Автотранспорт чараларын ял итү урыннарында, кешеләр күпләп җыела торган урыннарда, пляжларда, скверларда, шулай ук тротуарларда, газоннарда һәм шул максатлар өчен бүлеп бирелгән урамнарда туктату, автотранспорт чараларын йөртү һәм парковкалау юлы белән газоннарга, яшел үсентеләргә зыян салу тыела.»

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кирельск авылы, Гагарин урамы, 1 йорт (административ бина);

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кирельск авылы, Гагарин урамы, 14 йорт ("Раиф" кибете);

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кирельск авылы, Түбән ур., 6 йорт (китапханә)

4) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Ишем авылы, Үзәк ур., 10 (авыл клубы),

5) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Мордва Каратай авылы, Үзәк ур., 7 (КФҮ),

шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Кирельский авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Кирельский авыл җирлеге Советы Рәисе В.А.Лазарева